КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 февраль г.Казань № 164

Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендәге тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2014 ел, 30 октябрь, 822 нче карары белән расланган Россия Федерациясенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендәге тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендәге тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2014 ел, 30 октябрь, 822 нче карары (Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 июнь, 517 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Россия Федерациясенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендәге тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибенә, 1

пунктның «а» пунктчасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«а) түбәндәге эшчәнлек төрләрен лицензияләү (лицензияләр бирү, лицензия алырга теләүчеләрнең лицензия таләпләренә туры килүен бәяләү, «Кайбер эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда лицензияләр реестрына үзгәрешләр керткәндә лицензия алучыларның лицензия таләпләренә туры килүен бәяләү, лицензияләрне гамәлдән чыгару, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан бирелгән лицензияләр реестрларын булдыру һәм алып бару, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү, хәбәрнамәләр һәм лицензияләү барышында файдаланыла торган башка документлар формаларын раслау, шулай ук кызыксынучы затларга лицензияләү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү (бу мәгълүматтан файдаланучылар тарафыннан рәсми сораулар җибәрелә һәм соратыла торган мәгълүмат алына алган электрон почта адреслары күрсәтелгән әлеге мәгълүматны Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштыруны кертеп) өлешендә):».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин